**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**10 декабрь 2024 ел** **№ 155**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 12.02.2014 елның 121 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы федераль законнар, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 12.02.2014 елның 121 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 20 статьясындагы 3 өлешенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **М. Х. Туктаров**